[library stamp]

ЧАРШӘМБЕ
17 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 14 (5814)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

УКУ ЕЛЫНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫ

Уку елының икенче яртысы башланды. Мәктәп ишекләре яңадан ачылдылар. Аның якты, җылы һәм киң класслары шат күңелле балалар белән тулды.

Балалар үзләренең кышкы ялларын күңелле һәм файдалы итеп үткәрделәр. Бу көннәрдә алар елкаларда, киноларда, театрларда, музейләрдә булдылар, конькида, чаңгыда шудылар. Бөек Ватаныбыз үзенең кечкенә граждannарына яхшы укырга, культуралы һәм файдалы ял итәргә, үзләренең сәләтлекләрен һәр яклап үстерүгә тулы мөмкинлекләр бирде.

Балаларны коммунистик җәмгыят төзүдә актив катнашучы итеп тәрбияләүдә мәктәп төп урын булып тора. Мәктәптә отличнога уку – ул, производствода һәм колхоз кырларында стахановча эшләү кебек үк гаять зур әһәмиятле политик эш. Совет балалары моны бик яхшы аңлыйлар. Ленин—Сталин партиясенең һәм Совет хөкүмәтенең кайгыртучанлык күрсәтүләренә җавап итеп, алар бары тик отлично һәм яхшы уку өчен көрәшәләр.

Укытучыларның каникул вактында булып үткән конференцияләрендә уку елының беренче яртысына йомгак ясалды. Ярты еллык эш нәтиҗәсе совет мәктәбенең үткән елга караганда тагын да зуррак уңышларга ирешүен күрсәтте. Уку елының беренче яртысын югары өлгереш белән тәмамлаган мәктәпләрнең саны тагын да артты. Укытучылар коллективлары, тарихи XVIII нче съезд карарлары белән коралланган хәлдә, үз алларына куелган бурычны уңышлы үтәү өчен армый-талмый көрәшәләр.

Укытучылар конференцияләре мәктәпләрнең эшләрендә соңгы көнгә кадәр яшәп килгән зур кимчелекләрне дә бөтен тулылыгы белән ачты. Безнең мәктәпләребез икенче чиректә, беренче чирекә караганда зур уңышларга ирештеләр, ләкин шулай да аерым эш тармакларында зур кимчелекләр яшәп килә әле. Кайбер мәктәпләрдә отлично һәм яхшы уку өчен социалистик ярыш кирәгенчә оештырылмаган, дисциплина өчен көрәш җитәрлек түгел, политик-тәрбия эшләре тиешле югарылыкка күтәрелмәгән. Нәтиҗәдә, мондый мәктәпләр икенче чиректә дә түбән өлгереш белән тәмам иттеләр.

Уку елының икенче яртысын башлаган вакытта практик эштәге кимчелекләрне бетерүгә, балаларны укытуда һәм тәрбияләүдә тагын да яңа уңышларга ирешүгә, укуда өлгермәүчәнлекне бетерүгә нинди юллар белән барырга һәм нинди чаралар кулланырга кирәклеген һәрбер укытучы алдан ук белергә тиеш. Үткән конференцияләрдә күренгәнчә, мәктәптә һәм класста уңышларга ирешүне, беренче чиратта, укытучының үзенең хәл итүен һәрбер укытучы аңларга тиеш. Укытучы үз эшенең чын мастеры—югары квалификацияле укытучы, классның оста җитәкчесе, балалар арасында зур авторитет казанган тәрбияче, үз эшен намуслы рәвештә үтәүче булырга тиеш. Укытучы бу сыйфатлардан тыш совет балаларының белемнәрен күтәрүгә, отлично укуларына ирешә алмый һәм бигрәк тә, халык укытучысы дигән бөек исемгә ия була алмый. Педагогик процессны оештыруда укытучының төп фигура булуы турында партиябез тарафыннан бирелгән күрсәтмәнең әһәмияте хәзерге чорда аеруча зур.

Совет укытучысы балаларның турылыклы җитәкчесе һәм сөекле дусты булырга тиеш. Безнең алдынгы укытучыларыбыз моны бик яхшы аңлыйлар һәм алар укучы балаларга зур кайгыртучанлык һәм ихтирам белән карыйлар. Мондый укытучылар балаларны мәктәптә, урамда, семьядә үз-үзен яхшы тотуга, өйгә бирелгән эшне төгәл үтәүгә, социалистик милекне саклауга, үзеннән зурларга ихтирам белән карарга өйрәтәләр. Мондый укытучылар, шул ук вакытта, балалар алдына зур таләпләр дә куя беләләр. Тәртип бозучы, эшне үтәмәүче, тупаслык итүче балаларны алар тәртипкә чакыра беләләр.

Бер мисаль. 13 нче мәктәпнең (Сталин районы) VI нчы һәм VII нче классларында рус телен иптәш Ионин укыта һәм VII нче „А" классының җитәкчесе булып эшли. Иптәш Ионин җитәкчелек иткән класс уку елы башланганнан бирле мәктәп күләмендә беренче урында тора. Иптәш Ионин һәрбер укучының өйгә бирелгән эшне ничек үтәвен тикшереп чыга, әгәр дә берәр укучы өйгә бирелгән эшне үтәми килсә, ул аның ата-аналары белән сөйләшә, үтәмәүнең сәбәбен эзли, аны тикшерә һәм шуннан соң балага карата тиешле чараны күрә.

Педагогик процессны оештыруда, класста, мәктәптә югары өлгереш биргүгә ирешүдә эш тәҗрибәләрен уртаклашу укытучыларга гаять зур ярдәм итә. Ләкин Наркомпрос, аеруча, РОНО работниклары бу эшкә тиешле әһәмиятне биреп җиткермиләр әле. Моны практик эштә системалы рәвештә алып бару өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар. Алдынгы укытучыларыбыз һәм Хөкүмәтебезнең бөек бүләген алуга ирешкән—орденлы, медалле укытучыларыбыз үзләренең үрнәкле эш тәҗрибәләрен укытучылар коллективы белән уртаклашырга хәзер торалар. Тәҗрибә уртаклашуны оештыруда бары тик инициатива һәм җидди хәрәкәт, мәгариф органнары работникларыннан конкрет эш таләп ителә.

Уку елының икенче яртысы—ул, уку елының хәл иткеч чоры. Ул, укуда югары өлгерешне яулап алуның хәл иткеч чоры. Ләкин, укучылар арасында аңлы дисциплина булдырмый торып, югары өлгерешкә ирешеп булмый. Коммунистик җәмгыят төзүчеләр хәзерләүче Совет мәктәбенә, марксизм-ленинизмның бөек принциплары нигезендә төзелгән мәктәпкә дисциплинасызлык, җебегәнлек, тотнаксызлык, тәртипне бозу чит нәрсә. Яхшы уку, дисциплиналы булу өчен көрәш һәрбер укучының һәм һәрбер укытучының изге бурычы.

Совет балаларын бөек Ватаныбызга лаеклы кешеләр итеп тәрбияләү өчен укытучыга барлык кирәкле шартлар булдырылды. Кешелекнең бөек даһие иптәш Сталин бу мәсьәлә белән турыдан-туры үзе шөгыльләнә. Балаларны тәрбияләүдә укытучыга тулы ярдәм күрсәтүне партия Ленин комсомолы алдына бөек бурыч итеп куйды. Комсомол зур көч ул. Бу көчтән тулысынча һәм дөрес файдалана белергә һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының X нчы пленумы карарларының тормышка ашырылуы өчен нык лы көрәш җәелдерергә кирәк.

Уку елының үткән яртысы йомгакларыннан үзләре өчен тиешле нәтиҗәләрне ясап, укытучылар Совет мәктәбен бөек партиябез күрсәткән юл белән тагын да алга алып барырлар һәм уку елының икенче яртысында тагын да зуррак уңышларга ирешерләр.

КОМСОМОЛНЫҢ ӨЛКӘ КҮЛӘМЕНДӘГЕ АКТИВ ҖЫЕЛЫШЫ

16 нчы гыйнварда Менжинский исемендәге клубта комсомолның өлкә күләмендәге актив җыелышы башланды.

Җыелышта партиянең өлкә һәм шәһәр комитетларының, ВЛКСМ ның өлкә, шәһәр һәм район комитетларының җитәкче работниклары һәм башкалар катнашалар.

Комсомол активы почетлы президиумга ВКП(б) Үзәк Комитетының политбюро составын гаять зур күтәренкелек белән сайлады.

ВЛКСМ Үзәк Комитетының X нчы пленумы йомгаклары турында комсомолның өлкә комитеты секретаре иптәш А. Перов доклад ясады.

Доклад буенча фикер алышуларда Дәүләтшин, Гыйбадуллин, Ядгарова, Банковская, Аристов һәм башка иптәшләр сөйләделәр.

Актив җыелышы бүген кич үзенең эшен дәвам иттерә.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

15 нче гыйнварда **Мурманский, Ухта** һәм **Реболы** юнәлешләрендә разведчикларның эзләнүләре һәм аерым участкыларда мылтык-пулеметлардан һәм артиллериядән атышу булды.

Петрозаводский юнәлешендә пехота частьләренең бәрелешләре дәвам итте. **Карелия** бугазында разведка частьләренең хәрәкәтләре һәм сирәк-сирәк артиллерия атышуы.

Безнең авиация урны-урны белән тимер юл узелларын һәм сугыш объектларын бомбага тоту буенча күп кенә операцияләр үткәрде.

МОСКВА, КРЕМЛЬ

Иптәш СТАЛИНГА, Иптәш МОЛОТОВКА

Хәзер Сезнең җылы котлавыгызны алу вактында, йөрәкләребездә тулган дулкынлануны, шатлыкны һәм бәхетне белдерү өчен безгә сүзләр табуы кыен.

Хәрәкәтебезнең бер генә минутында да без ул хәрәкәтнең уңышлы төгәлләнәчәгенә ышанычыбызны югалтмадык, чөнки без партиянең, хөкүмәтнең безнең турыда көндәлек кайгыртучанлык күрсәтүен һәм, Иосиф Виссарионович һәм Вячеслав Михайлович, Сезнең үзегезнең игтибар биреп торуыгызны без сизә идек. Илебез, партия һәм иптәш Сталин совет кешеләрен, алар нинди генә кыен шартларда булсалар да, ташламаячакларын без нык рәвештә белдек һәм, үзебезгә тапшырылган эшкә бөтен көчләребезне һәм белемнәребезне биреп, совет фәнен тагын да баетырга тырышып, тыныч эш алып бардык.

Сезнең игтибарыгыз һәм кайгыртучанлык күрсәтүегез безне гүзәл Ватаныбызның даны өчен, коммунизмның тантанасы өчен яңа кыен эшләргә рухландыра.

Кадерле Иосиф Виссарионович һәм Вячеслав Михайлович, Сезгә кайнар рәхмәт белдерәбез, кешелек дөньясының шатлыгы һәм бәхте өчен Сезнең озак һәм озак еллар буе сәламәт яшәвегезне һәм эшләвегезне телибез.

„Г. Седов" бозваткыч пароходы экипажының тапшыруы буенча

Бадигин.
Трофимов.

Гренландия диңгезе, „И. Сталин" бозваткычы борты. 15 гыйнвар, 1940 ел.

МОСКВА, КРЕМЛЬ

Иптәш СТАЛИНГА, Иптәш МОЛОТОВКА

Радио безгә Зур Җирдән Сезнең җылы котлау һәм игтибар күрсәтү сүзләрегезне китергән вакытта, безне бөек шатлык һәм горурлык хисләре чолгап алды. Безгә Ватанның, партиянең һәм, Сталин һәм Молотов иптәшләр, Сезнең үзегезнең мактаулы йөкләмәгезне үтәү эше—югары мактаулы эш тапшырылу белән бәхетлебез. Безнең экспедициянең уңышы—ул безнең данлыклы большевиклар партиясенең, күп милләтле бөтен совет халкының җиңүе. Без—шул халыкның уллары.

„И. Сталин" флагман бозваткычының коллективы „Г. Седов" бозваткыч пароходын бозлар пленлегеннән чыгару операциясенең икенче өлешен үтәү эшенә гаять зур күтәренкелек белән керешә. Партия һәм хөкүмәтнең игтибары һәм кайгыртучанлык күрсәтүе белән рухланган хәлдә, без Сезне ышандырабыз: операциянең икенче өлешен дә мактаулы рәвештә үтәрбез һәм Советның легендар арктика карабын бөек Ватаныбызның ярлары буена китерербез һәм Совет җиренең унбиш батыр улын—социалистик Ватанның чын патриотларын Совет җиренә кайтарырбыз.

Арктика линкорның—Совет бозваткыч флоты флагманының коллективы Сезне—халыклар юлбашчысын һәм Совет Хөкүмәтенең башлыгын ышандыра: бөек Ватаныбызның боз чикләрендә бу коллектив киләчәктәге көрәшләргә хәзер, Сезнең теләсә нинди заданиегезне үтәүгә, Үзәк Котып бассейнының океан һәм диңгез иркенлекләрендә теләсә нинди эш алып баруга хәзер.

Яшәсен сөекле Ватаныбыз!

Яшәсен җиңелмәслек Ленин—Сталин байрагы!

„И. Сталин" бозваткычындагы экспедиция составының тапшыруы буенча

И. Папанин.
М. Белоусов.

Гренландия диңгезе, „И. Сталин" бозваткычы борты. 15 гыйнвар, 1940 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫНЫҢ УКАЗЫ

19 НЧЫ СТРЕЛКОВЫЙ ПОЛКНЫ „КЫЗЫЛ БАЙРАК" ОРДЕНЫ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘҮ ТУРЫНДА

Фин ак гвардиячелегенә каршы көрәш фронтында командованиенең хәрби заданиеләрен үрнәк рәвештә үтәве өчен һәм бу эштә каһарманлык һәм батырлык күрсәтүе өчен 19 нчы стрелковый полкны **„Кызыл байрак"** ордены белән бүләкләргә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль 15 гыйнвар, 1940 ел.

МТС һәм МТМ алдынгыларының РЕСПУБЛИКА ПОЧЕТ ТАКТАСЫ

ВКП(б) райкомнарының һәм хезмәт ияләре депутатлары советларының район башкарма комитетлары күрсәтүе буенча тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауда яхшы күрсәткечләр биргән алдынгылар һәм стахановчылар Республика Почет Тактасына кертеләләр:

10. Алабуга районының **Алабуга промсовхозы.** 1940 нчы елның 5 нче гыйнварына тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны тулысынча төгәлләде. Промсовхозның директоры иптәш **Вильданов,** агроном иптәш **Кондренков,** механик иптәш **Матвеев.**

11. Алабуга промсовхозының ремонтта эшләп чыгару нормаларын һәр көнне 200 процентка үтәгән тракторчылары **Юшков** һәм **Хабанский** иптәшләр.

12. Балык Бистәсе районы, Балык Бистәсе МТС ының 1940 нчы елның 5 нче гыйнварына үз бригадасында тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны тулысынча тәгәлләгән трактор бригадасы бригадиры иптәш **Козлов,** аның ярдәмчесе иптәш **Артомонов** һәм шул ук бригаданың тракторчылары **Вотяков** һәм **Клементьев** иптәшләр.

13. Әлки районы, Базарлы Матак МТС ының үз бригадаларында тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны 1939 нчы елның 29 нчы декабренә тулысынча тәгәлләгән трактор бригадаларының бригадирлары **Галиуллин Х.** һәм **Хәйдәрев** иптәшләр.

14. Беренче Май районы, Беренче Май МТМ ының ремонт ясауда эшләп чыгару нормаларын һәр көнне 165 процентан 200 процентка кадәр үтәгән эшчеләре токарь **Ш. Ш. Шәмгунов,** слесарь **Н. А. Зябдов,** слесарь **И. Н. Губернаторов** иптәшләр.

„И. Сталин" бозваткычы капитаны иптәш Белоусов бозваткыч бортында.
Д. Дебабов фотосы (ТАСС фото-клишесе).

ССР СОЮЗЫ ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫНЫҢ УКАЗЫ

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ КЫЗЫЛ АРМЕЕЦЛӘРЕНӘ ҺӘМ НАЧАЛЬНИКЛАР СОСТАВЫНА СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ ДИГӘН ИСЕМНЕ БИРҮ ТУРЫНДА

Фин ак гвардиячелегенә каршы көрәш фронтында командованиенең хәрби заданиеләрен үрнәк рәвештә үтәүләре өчен һәм бу эштә батырлык һәм геройлык күрсәткәнлекләре өчен, Ленин ордены һәм „Алтын йолдыз" медале тапшырып, түбәндәгеләргә **Советлар Союзы Герое** дигән исемне бирергә.

1. Кызыл армеец Владимир Кузьмич **Артюх.**
2. Кече командир Василий Петрович **Бахвалов.**
3. Өлкән лейтенант Никифор Григорьевич **Большаков.**
4. Лейтенант Виктор Константинович **Булавский.**
5. Комбриг Петр Евгеньевич **Вещев.**
6. Кече командир Борис Васильевич **Волк.**
7. Кызыл армеец Кузьма Дмитриевич **Высоцкий.**
8. Кече командир Василий Иванович **Гал хов.**
9. Лейтенант Василий Григорьевич **Груздев.**
10. Полковник Владимир Нестерович **Кошуба.**
11. Кече лейтенант Николай Григорьевич **Кичигин.**
12. Кызыл армеец Иван Михайлович **Комаров.**
13. 2 нче ранг воентехник Иван Иванович **Коваль.**
14. Кече командир Григорий Михайлович **Лаптев.**
15. Кече командир Михаил Андреевич **Ларченко.**
16. Кече командир Михаил Абрамович **Лобастев.**
17. Кече командир Федор Иванович **Лопатин.**
18. Кече командир Евгений Алексеевич **Луппов.**
19. Өлкән лейтенант Давид Львович **Маргулис.**
20. Кызыл армеец Николай Никитич **Никитин.**
21. Кызыл армеец Григорий Степанович **Пулькин.**
22. Лейтенант Михаил Матвеевич **Родичев.**
23. Кызыл армеец Карпет Семенович **Симонян.**
24. Кызыл армеец Иван Михайлович **Соломонников.**
25. Кече лейтенант Павел Васильевич **Усов.**
26. Кызыл армеец Иван Михайлович **Ульянов.**
27. Капитан Николай Степанович **Угрюмов.**

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль. 15 гыйнвар, 1940 ел.

Кызыл Армиянең гаскәри частьләрен, начальниклар составын һәм кызыл армеецләрне бүләкләү турында

Фин ак гвардиячелегенә каршы көрәш фронтында командованиенең хәрби заданиеләрен үрнәк рәвештә үтәгәнлекләре өчен һәм бу эштә күрсәткән батырлыклары һәм геройлыклары өчен, ССР Союзы Верховный Советы Президиумының указы белән, 27 командирга һәм кызыл армеецкә **Советлар Союзы Герое** дигән исем бирелде. Бер үк вакытта аларга Ленин ордены һәм „Алтын йолдыз" медале тапшырылачак.

Фин ак гвардиячелегенә каршы көрәш фронтында командованиенең хәрби заданиеләрен үрнәк рәвештә үтәве өчен һәм бу эштә үзенең личный составы каһарманлык һәм батырлык күрсәткән өчен, ССР Союзы Верховный Советының Президиумы 19 нчы стрелковый полкны „Кызыл байрак" ордены белән бүләкләде.

Фин ак гвардиячелегенә каршы көрәш фронтында командованиенең хәрби заданиеләрен үрнәк рәвештә үтәүләре өчен һәм бу эштә күрсәткән каһарманлыклары һәм батырлыклары өчен СССР Верховный Советы президиумы, аерым указлар белән, 2.606 кешене Советлар Союзының орденнары һәм медальләре белән бүләкләде. Шулар арасында: Ленин ордены белән 38 кеше, „Кызыл байрак" ордены белән 713 кеше, „Кызыл йолдыз" ордены белән 377 кеше, „Батырлык өчен" медале белән 317 кеше, „Сугышчан хезмәт күрсәткән өчен" медале белән 661 кеше бүләкләнделәр.

Бүләкләнгән барлык кешеләрнең исемлеге „Правда", „Известия" һәм „Красная Звезда" газеталарында иглан ителә.

Бу бүләкләү Ленин—Сталин партиясенең һәм Совет хөкүмәтенең Кызыл Армиягә кайнар мәхәббәт күрсәтүенең яңа билгесе, үз Ватаннарының даны өчен каһарманлык һәм батырлык белән, үзләренең каннарын һәм хәтта тормышларын кызганмыйча, командованиенең хәрби заданиеләрен үрнәк рәвештә үтәүче сугышчыларның, командирларның, комиссарларның һәм политработникларның хәрәкәтләренә партиянең һәм хөкүмәтнең югары бәя бирүенең яңа күрсәткече булып тора.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

АВЫЛ КОММУНИСТЛАРЫ

Әлмәт районы, Буденный исмендәге колхоз янындагы партоешма иң яхшы кешеләрне партиягә сайлап алу һәм яш коммунистларны тәрбияләү буенча зур эш алып бара. Партоешма 1939 нчы елның 11 ае эчендә ВКП(б) членлыгына кандидат итеп 17 кешене кабул итте.

Партоешма ВКП(б) сафларына керергә теләүче һәрбер иптәш белән алдан ныклап таныша һәм аларга партиягә керү өчен конкрет ярдәм күрсәтә. Партия оешмасы турыдан-туры колхоз производствосында эшләүче стахановчыларны партиягә кабул итү эшенә аеруча игътибар бирә. Партиягә кабул ителгән 17 кешенең 11 е колхозчы - стахановчылар.

Партоешма хатын-кызларны ВКП(б) сафларына тарту буенча үзенең йомшак эшләвен искә алып, күптән түгел бу мәсьәләне гомуми җыелышка куеп тикшерде. Шуннан соң хатын-кызлар арасында политик-тәрбия эшләре шактый дәрәҗәдә яхшырды. Хәзер партоешма тирәсенә хатын-кызлардан ныклы актив тупланды. Колхозның стахановчысы В. Квасова, комсомол члены А. Николаева һәм башка иптәшләр ВКП(б) сафларына керергә хәзерләнәләр.

Яш коммунистлар җәмагат эшләрендә актив катнашалар һәм үзләренең политик белемнәрен күтәрү өстендә тырышып эшлиләр. Мәсәлән, иптәш Плягинга хәзер 55 яш. Ул кандидатлар өчен оештырылган түгәрәккә системалы рәвештә йөри. Иптәш Плягин җирле Советларга сайлау кампаниясе вактында 4 нче сайлау округында комиссия председателе булып эшләде. Ул эшләгән округта масса-аңлату һәм оештыру эшләре башкаларга үрнәк булырлык итеп куелган иде. Кәлимуллин һәм Сәхипов иптәшләр сайлау участкыларында агитатор булып эшләделәр. Алар сайлаучылар арасында сайлау законнарын өйрәнү эшен, ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларын һәм СССР Верховный Советы сессияләре материалларын өйрәнү белән бергә бәйләп алып бардылар. Сайлау округларында агитатор булып эшләгән иптәшләр хәзер дә үзләренең эшләрен дәвам иттерәләр. Алар колхозчылар арасында халыкара хәл турындагы мәсьәләләр буенча беседалар үткәрәләр.

Коммунистлар хезмәткә социалистик карашның яхшы үрнәкләрен күрсәтәләр. Коммунистлардан Томясов, Юртов, Шомин һәм башка иптәшләр колхозда йөзпотчылар хәрәкәтенең инициаторлары булып торалар. Колхоз югары иген уңышы өчен көрәштә 3 ел инде районда беренче урынны алып килә. Партоешма практик эштә сыналган колхозчы коммунистларны җитәкче эшләргә күтәрү мәсьәләсен дә онытмый. Иптәш Юртов киндерчелек эшендә звеновод булып эшли иде. Хәзер ул бригадир итеп күтәрелде. Бригада членнары арасында масса-аңлату эшләрен яхшы кую һәм хезмәтне дөрес оештыру нәтиҗәсендә, аның бригадасы хуҗалык эшләрен колхозда беренче булып тәгәлләде. Рядовой колхозчы, алдынгы стахановчы иптәш Квасов ферма мөдире итеп куелды. Бригадир иптәш Шомин колхоз председателе итеп сайланды. Алар барсы да үз эшләрендә зур җаваплылык сизәләр, партия оешмасы тарафыннан йөкләтелгән бурычларны намус белән акларга тырышалар.

Партоешманың эшендә кимчелекләр дә бар әле. „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н оешмадагы 20 коммунистның 7 се үзлегеннән өйрәнә. Һәм калган 11 кеше түгәрәккә тартылган. Ләкин партоешма (секретаре иптәш Ханнанов) аларга җитәрлек ярдәм оештырмый әле. Мәсәлән, консультацияләр бик сирәк була. Уку йортында әдәбият һәм күргәзмә материаллар җитәрлек түгел. Партия тарихын өйрәнү буенча тәҗрибәләрне уртаклашу эшләре оештырылмый. Партиягә яңа кабул ителгән иптәшләр арасында аз укый-яза белүчеләр бар. Алар күптән инде үзләренең гомуми белемнәрен күтәрү буенча укулар оештыруны таләп итәләр. Ләкин партоешма бу теләкне үтәгәне юк әле.

З. Салахи.

ПАРТИЯ ГРУППАЛАРЫНА ЖИТӘКЧЕЛЕКНЕ КӨЧӘЙТИК

Партиянең XVIII нче съезды тарафыннан кабул ителгән ВКП(б) уставында партиядән тыш оешмалар янындагы партия группаларының бурычлары турында болай диелгән: „...аларның бурычы—партиясезләр арасында партиянең йогынтысын һәр яклап көчәйтү һәм аның политикасын үткәрү, партия һәм дәүләт дисциплинасын ныгыту, бюрократизмга каршы көрәшү, партия һәм совет директиваларының үтәлешен тикшерү".

Мамадыш районында партиядән тыш оешмалар янындагы партия группаларының күбесе үзләренә йөкләнгән бу бурычларны үтәү өчен тиешенчә көрәшмиләр әле. Мисаль өчен райпотребсоюз янындагы партия группасын алырга мөмкин. Бу группаның оештырылуына ун айдан артык вакыт узуга карамастан, аның бары бер тапкыр җыелышы булган. Партгруппа сәүдә работниклары арасында политик-тәрбия эшләрен оештыру һәм растраталарга каршы көрәш алып бару мәсьәләсе белән тиешенчә шөгылләнми. Партгруппаның кайбер членнары райпотребсоюзның эше белән бөтенләй кызыксынмыйлар. Мәсәлән, иптәш Мөстакыймов сайлаулар узганнан бирле правление утырышында бер тапкыр да катнашмаган. Районда кооперация демократиясен бозу һәм растрата ясау фактлары бар. Райпотребсоюз правлениесе үзенең сайлаучылары алдында бер тапкыр да отчет ясамаган. Сәүдә работникларыннан 28 кеше кооперациянең 35 мең сумнан артык акчасын туздырган.

Партия группаларына ВКП(б) райкомының җитәкчелеге һич тә канәгатьләнерлек түгел. Узган елны өч группаның эше райком тарафыннан бер дә тикшерелмәве моны бик ачык күрсәтә.

Партия группаларына болай игътибарсыз карауны бетерергә күптән вакыт. ВКП(б) ның Мамадыш райкомы партия группалары белән җидди рәвештә шөгылләнергә һәм аларның эшенә көндәлек рәвештә ярдәм күрсәтергә тиеш. Партия группаларына ВКП(б) уставы буенча йөкләнгән бурычларның тулысынча үтәлүенә ирешергә кирәк.

Г. Мостафин.

ЗАВОД КОМСОМОЛЕЦЛАРЫ

Максим Горький исмендәге завод янындагы комсомол оешмасы алдынгы яшьләр хисабына туктаусыз үсә. Комсомол оешмасы 1939 нчы елны ВЛКСМ сафларына 172 кешене кабул итте.

Партия оешмасы алдынгы комсомолецларны ВКП(б) сафларына кабул итү эшенә зур игътибар бирә. Үткән ел 24 комсомолец ВКП(б) членлыгына кандидат итеп кабул ителде.

Комсомолецлар оборона һәм физкультура эшләре белән нык кызыксыналар. Соңгы вакытта гына да комсомолецлардан 148 кеше Осоавиахимга член булып керде һәм 94 кеше ГТО значогына нормалар тапшырды.

Завод комсомолецлары производствода авангардлык үрнәкләре күрсәтәләр. Гришин, Әхмеров, Салахов, Гусев, Евграфов, Миндров иптәшләр көнлек эш нормасын 200 процент итеп үтиләр.

М. Халиков.

ЯШ КОММУНИСТЛАР ЖИТӘКЧЕ ЭШЛӘРДӘ

Казан шәһәрендә балык базасы янындагы башлангыч партоешма алдынгылар хисабына үсә. Оешма соңгы өч айда ВКП(б) членлыгына кандидат итеп 4 кешене кабул итте.

Партиягә яңа алынганнардан күп кенә иптәшләр җитәкче эшләргә күтәрелделәр. Мисаль өчен иптәш Идрисовны алырга мөмкин. Ул, базаның гади эшчесе, стахановчы иде. Кадрлар хәзерләү курсын отличнога тәмам иткәннән соң, ул приозводство бүлеге мөдире итеп күтәрелде. Үзенә йөкләнгән бу җаваплы эшне намус белән үти. Производствода стахановчылык хәрәкәтен җәелдерүдә зур тырышлык күрсәтә һәм стахановчыларга ярдәм итә. Җәмагат эшенә актив катнаша. Иптәш Идрисов, яхшы эшләве өчен СССР Балык Промышленносты идарәсе тарафыннан „Стахановчы значогы" белән бүләкләнде.

Ул, үзенең теоретик белем дәрәҗәсен күтәрү өстендә дә тырышып эшли. „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н үзлегеннән өйрәнә.

Менә иптәш Сабитов. Ул, магазин директорлары хәзерләү курсын уңышлы тәмамлады һәм балык магазиннарында бүлек мөдире булып эшли. Бу бүлек үз планын һәр айны арттырып үти.

С. Баталов.

„ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н түбәнге звено буенча өйрәнүчеләр өчен Мехкомбинатта оештырылган түгәрәк членнары, (сулдан): М. Я. Чумарова, К. В. Устинова, И. Ф. Щербаков, Е. Т. Иколаев, В. С. Куликов (түгәрәк җитәкчесе) һәм М. Ф. Выборнова иптәшләр түгәрәкнең чираттагы занятиесендә.

И. Галиев фотосы.

МАТБУГАТ КҮЗӘТҮ

КҮРГӘЗМӘ ТУРЫНДА ОНЫТКАННАР

Узган елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә Әтнә районыннан 11 колхоз һәм күп санда колхоз алдынгылары катнашты. Районның Ленин исмендәге һәм Киров исмендәге колхозлары беренче дәрәҗә диплом белән бүләкләнделәр. Шул уңай белән Киров исмендәге колхозда булып үткән митингта колхозчылар болай дип белдерделәр:

„Партия һәм хөкүмәтебезнең бүләгенә җавап итеп, колхозда хезмәт дисциплинасын бер туктаусыз ныгытырбыз, социалистик ярыш һәм стахановчылык хәрәкәтен тагын да киң җәелдерербез. Агротехника чараларын киң кулланып, тагын да мул уңышлар яулап алу өчен армый-талмый эшләрбез".

Ленин исмендәге колхоз членнары шулай ук:

„... Әйдәгез, иптәшләр, намус белән эшлик, 1940 нчы елда да күргәзмәгә катнашу хокукын яулап алыйк!",—дип мөраҗәгать иттеләр!

Бу цитаталарны без Әтнә район газетасының („Социализм Юлы") үткән елның 29 нчы октябрендә чыккан номерыннан китердек. Авыл хуҗалыгы күргәзмәсен пропагандалауда газетаның бу номеры бай эчтәлекле һәм игътибарны үзенә тартып тора. Без газетаның шуннан соңгы номерларын да карап уңышлы тәҗрибәләр белән уртаклашу максатын алга куйдык. Кызганычка каршы, нәтиҗә башкача булып чыкты: газета шуннан соң күргәзмә турында бер генә сүз дә язмаган.

Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә быел катнашу өчен районда хәзерлек барамы соң? Билгеле, хәзерлек юк түгел.

Күргәзмәдә катнашу хокукын сорап Әтнә районыннан 40 ка якын гариза бар иде. Колхозлар һәм колхозчылар үзләренең гаризаларында социалистик авыл хуҗалыгы өлкәсендә яулап алган уңышлары турында язалар. Гариза бирүчеләр арасында: Ленин исмендәге колхозның стахановчысы Кәрим Салихов, Тельман исмендәге колхозда агролаборатория эшен отлично оештыручы Әсма Корбанова иптәшләр, Киров исмендәге колхоз һәм башкалар бар.

Узган елда күргәзмәдә катнашкан һәм беренче дәрәҗә диплом алган Киров исмендәге колхоз 1938 нче елда арыш мәйданының һәрбер гектарыннан 11,65 центнер уңыш алган булса, узган елны—12,4 центнер уңыш алуга ирешкән. Бөртекле культуралар буенча колхоз соңгы 3 ел эчендә гектардан һәр елны уртача 13,2 шәр центнер уңыш алып килә. Бу колхозның бөтен тармаклары буенча эш тәҗрибәләре күргәзмәнең Татарстан павильонында киң күләмдә күрсәтеләчәк. Кировчыларның яулап алган казанышларын популярлаштыру белән, ни өчендер, район газетасы шөгылләнми.

Кайбер газеталар күргәзмә турында язсалар да, аны бары тик кампания төсендә генә алып баралар. Мәсәлән, „Күмәк хуҗалык" (Мөслим районы) газетасы август, сентябрь айларында берничә материал урнаштыргач, бу мәсьәләне оныта. 12 нче декабрьдә чыккан номерында „1940 нчы елда да күргәзмәдә катнашу хокукын яулап алу өчен" дигән мәкалә урнаштырылган, аннан соңгы номерларда бу турыда тагын тынычлык хөкем сөрә. Ә бит Мөслим районыннан быел күргәзмәдә катнашуны сорап 122 гариза бирелгән. Аларның саны торган саен арта бара. Моны тик район газетасы работниклары гына күрмиләр.

Күргәзмәгә катнашучыларның күрсәткечләре авыл хуҗалыгында яңадан-яңа җиңүләргә өнди һәм шуңа көчле этәргеч булып тора. Социалистик авыл хуҗалыгының бөек казанышларын үзендә чагылдырган, бөтен кешелек дөньясының мәхәббәтен казанган бу гүзәл мәктәп—Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсе турында газеталар тулы, системалы язып торырга тиешләр һәм моңа алар бурычлылар.

Авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә катнашучыларны сайлап алу эше 1 нче мартка төгәлләнергә тиеш. Күргәзмәгә катнашуга лаеклы колхозларны һәм колхозчыларны, МТС һәм совхоз работникларын хәзер газеталарда киң күләмдә күрсәтергә кирәк.

ВКП(б) Өлкә Комитетында

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты бюросының карары белән түбәндәгеләр ВКП(б) сафларыннан чыгарылдылар:

Н. П. Антонов (п/б. № 2943565) бер ел ярымга иркеннән мәхрүм ителүгә хөкем ителүе һәм җәза үтәү срогында булганга.

Х. И. Ибраһимев (п/б. № 2942767) социалистик милекне урлавы өчен.

Г. С. Салихов (к/к. № 0755175) партиядән аерылуы һәм ике ел ярым буена членлык взносын түләмәгәнлеге өчен.

М. И. Мөхәмметҗанов (п/б. №1625594) партия оешмасын алдавы һәм ВКП(б) уставын тупас рәвештә бозуы өчен.

Г. П. Чертанов (к/к. № 0950094) кандидатлык карточкасын югалтуы һәм партия дисциплинасын тупас рәвештә бозуы өчен.

В. М. Быстриков (к/к. № 1295327) системалы рәвештә эчү белән шөгыльләнүе өчен.

С. К. Леонов (п/б. № 1635368) бер ел ярымга иркеннән мәхрүм ителүгә хөкем ителгән булуы һәм ябылуда булуы өчен.

Я. Н. Дунаевский (п/б. №1625346) партия билетын югалтуы һәм Осоавиахим акчасын туздыруы өчен.

М. С. Миронов (п/б. № 2942028) политик хулиганлыгы һәм партиягә каршы сөйләве өчен.

Н. Ф. Симонов (к/к. № 0757662) исрек хәлендә кандидатлык карточкасын югалтуы өчен.

А. В. Потапов (к/к. № 0952598) кардәшеннән урланган утын алуы һәм ул фактны партия оешмасыннан яшерүе өчен.

ХӨСӘЕН ЯМАШЕВ

Хөсәен Ямашев 1882 нче елның 6 (19) нчы гыйнварында Казанда урта дәрәҗәле сәүдәгәр семьясендә туа. 8 яшендә аны „Мәрҗания" мәктәбенә укырга бирәләр. Соңрак Мөхәмдия мәдрәсәсенә күчеп, аны тәмам итә. Яштән үк зирәк, яңалыкка, турылыкка омтылучы Хөсәенне, мәдрәсә белеме генә канәгатьләндерми. Ул русча укырга, фәнгә омтыла һәм 1897 нче елның беренче декабрендә Казан Татар Учительский школасына укырга керә. Анда 1902 нче елның 28 нче маена кадәр булып, школаны бөтен фәннәр буенча отлично билгесе белән тәмам итеп чыга.

Бергә укучы иптәшләре аның табигатен, аңлылыгын чын күңелдән яратканнар. Ямашевның яштәш иптәшләреннән берсе Хөсәеннең үлүенә бер ел тулу уңае белән язган истәлегендә: „... Без һәммәбез аны якын дус, безгә яхшылык теләүче иптәш дип белеп, аңар таба омтыла идек, аның якынында булырга тырыша идек, вә аның тирәсенә җыела идек[1]" ди. Ул шул еллардан үк укучы яшьләр арасында революцион фикерләр тарату буенча эшкә башлый. Соңгарак Алафузов, Пороховой заводы эшчеләре арасында түгәрәкләр оештырып, аңлату эшләре алып бара башлый.

Мәктәпне тәмам иткәннән соң да (1902 нче елны) укуын дәвам иттерә, университетка хәзерләнә. Үзлегеннән хәзерләнеп программа буенча экзамен тота. Ләкин ул вакытлардагы социал-политик хәлләр Хөсәенне беренче чиратта партия эшенә тарта. Ул 1903 нче елдан башлап тулысы белән партия эшенә бирелә. РСДРП ның Казан оешмасында эшли. Ямашевның бу чордагы эшләрен күп кенә тарихи документлар раслыйлар. Шуларның берсе һәм иң әһәмиятлесе—1905 нче елда Женевада В. И. Ленин җитәкчелегендә чыккан „Пролетарий" газетасының 22 нче номерында басылган. Анда большевикларның Казан Комитетының татарлар арасындагы эше турында түбәндәге бәя бирелә.

„... Комитетның эше татарлар арасында да алып барыла. Алар аерым районга бүленмәгәннәр, аларның алдынгы кешеләре башкалар белән берлектә оештыру группаларына керәләр, кайберләре рус түгәрәкләренә йөриләр; барсы да гомуми массовкаларга йөриләр. Ләкин тел аерым булганлыктан, түгәрәкләрне татар телендә дә үткәрергә һәм, соңыннан оешмага тарту өчен, кай вакыт башлангыч оештыру җыелышларын татарлар белән генә үткәрергә туры килә. Листокларны татар теленә тәрҗемә итәргә кирәк, аларны да татарлар гына басып чыгара алалар. Моның өчен К. (омитет) янында оештыручы татар бар, аның фикерләренә комитетта бик яхшы бәя бирелә. Казан халкының 30 проценты татарлар булуын искә алганда, бу бик аңлаешлы нәрсә. Шуның белән бергә, ул „ортодоксаль" караштагы төпле социал-демократ, анда аз гына да милләтчелек әсәре юк" („Пролетарий" газетасы №22, 11 октябрь, 1905 ел).

Бу документта Ямашев исме, ул чордагы политик хәл шартларыннан чыгып, ачыктан-ачык әйтелмәгән, ләкин анда характеристика бирелгән оештыручының Хөсәен Ямашев булуында шикләнерлек урын юк. Аның эшчәнлегенә карата шундый ук фикерләрне хәзерге вакытта исән булган карт большевик Николай Накоряков иптәш тә раслый.

1905 нче ел революциясе көннәрендә массага таратылган революцион прокламацияләр татар теленә дә тәрҗемә ителәләр. Болар арасында: авыл халкына, 9 нчы гыйнвар вакыйгасе турында һәм башкалар бар. Шул прокламацияләрне татарча язучы, тәрҗемә итүче Х. Ямашев була. 9 нчы гыйнвар канлы вакыйгаләреннән соң, бөтен Россияне чолгап алган революцион күтәрелеш Казанда да көчле була. Казанда 6 нчы июль вакыйгаләре соңыннан 30 нчы октябрь, 1 нче ноябрь күтәрелешләре зур бәрелеш көннәре булалар. Бу вакытларда большевиклардан Лозовский, И. А. Саммер иптәшләр Казан оешмасында эшлиләр. 1905 нче елның 11 нче декабрендә Петербург полиция департаментыннан бирелгән бойрык буенча Казан губерна жандармериясе партия җитәкчеләрен эзәрләүне көчәйтә һәм кулга ала башлый. 12 нче декабрьдә (1905 нче ел) Хөсәен Ямашев квартирасында да тентү була, аны кулга алырга ордер бирелгән була. Ләкин Х. Ямашев өйдә кунмаганлыктан, жандарм кулына төшүдән котыла. Ул яшерен хәлдә, 1906 нчы елның башларына кадәр Казанда яши һәм соңыннан революцион эшен дәвам иттерү максаты белән Уфага китә. Уфада ул, большевиклар комитетында эшли. Шушы вакытларда, Х. Ямашевның инициативасы белән, татар телендә газета чыгару мәсьәләсе куела. Уфа комитеты газета чыгаруны һәм шуның янында политик брошюралар бастырып таратуны кирәкле дип таба. Үзәк Комитеттан вәкил булып Уфага килгән А. И. Саммер да бу эшкә санкция бирә, партия кассасыннан акча бирдерә. Шул рәвешчә, татар телендә беренче большевистик газета булган „Урал" (4/1 1907 ел) газетасы оештырыла. Политик брошюралар һәм газетаның кайбер номерлары Уфада хәзерләнә. Ә бастырылуы Оренбургта була. Уфада басылмыйча, Оренбургта басылуының сәбәбен, Н. Накоряков иптәш Оренбургтагы техник мөмкинлектән һәм Ямашев иптәшнең анда танышлары булудан, дип аңлата. Кара реакция елларында бу газетага озак яшәргә мөмкинлек булмый, 31 номер чыкканнан соң, шул ук елның апрель урталарында патша хөкүмәте тарафыннан туктатыла һәм Х. Ямашев судка бирелә.

Газетаның политик юнәлешен күз алдына китерү өчен аның беренче номерында редакция тарафыннан язылган мәкаләне китерик:

„Россиядә иске тәртипкә каршы булган көрәш... Хәзер бөтен халыкның эшенә әйләнә бара, ягни иске тәртипкә каршы көрәш тирәнләнә барадыр.

Шулай ук бу көрәштә халыкның төрле сыйныфларның арасындагы каршылык көннән-көн өскә чыга бара.

Хәзер эшчеләр сыйныфының бурычы үзен сыйнфи дошманнарыннан алдатмыйча, бу көрәшне ахрына чаклы җиткезергә, үзенең олуг булган теләге социализм өчен көрәш ачудыр.

Безнең өчен пролетариат (эшчеләр сыйнфы) берләшкән һәм сыйнфына билгеле файдаларын аңлаган булырга тиешле.

Икенчә яктан, бу көрәшне ахрына кадәр җиткерү, бу көрәш пролетариатның якын иптәше булырлык крестьян халкының һәм шәһәр җирләрендәге фәкыйр халыкның үзләренең файда вә зарарларын аңлаулары артудан һәм үзара берегешеп кушылуларыннан булачактыр.

Шуңа күрә без үземезнең газетамызда пролетариатны бергә кушылуга өндәп, аның сыйнфына билгеле аңын арттыруга булышу кеби крестьян халкын һәм шәһәр фәкыйрләрен дә үзара кушылырга өндәячәкбез".

Монда куелган мәсьәләләр аңлатма бирүгә мохтаҗ түгелләр, алар партиянең ул вакыттагы теләкләрен чагылдыралар, көрәшне дәвам иттерергә чакыралар. Газетаның соңгы номерларындагы мәкаләләр „Мөселман иттифакы" партиясенә, гомумән, милләтчеләргә каршы көрәшкә багышланган. „Сул" һәм „Кызыл" псевдонимы белән язылган мәкаләләр һәм бик күп имзасыз мәкаләләр Хөсәен Ямашев каләме белән язылганнар. „Урал" редакциясе янында болардан тыш түбәндәге политик брошюралар да басылып таратыла:

1. — „Эшчеләрнең котылуы үзләренең эше булырга тиеш".
2. „Төрле милләтләрне җәберләү кемгә кирәк".
3. „Гомуми сайлау правосы".
4. „Россия социал-демократлары авыл крестьяннәре өчен нәрсә булдырырга тырышалар".
5. „Безнең якында булдырырга теләгән нәрсәләребез һәм төп максатыбыз".

Х. Ямашев Оренбургтан яңадан Уфага кайта. 1907 нче елның беренче августында Казан университетының юстиция факультетына алуны сорап Уфадан гариза җибәрә. Аның гаризасы 50 көн буенча йөртелеп, төрле резолюцияләрне үтә, политик ышанычлыгы турында таныкнама һәм рәсмен сорыйлар. Соңыннан 19 нчы сентябрьдә төп документларны китерү шарты белән алырга дигән резолюция салына. Шул елның беренче яртысында ирекле тыңлаучы булып, хокук һәм тарих фәннәре буенча лекцияләр тыңларга языла. Хөсәен бу елларда Казандагы демократик көчләрне, бигрәк тә язучыларны, үз тирәсенә туплый. Г. Тукаев, Г. Камал һәм Г. Коләхметовлар аның якын иптәшләре булалар һәм бергә эшләүне дәвам иттерәләр. Ул соңгы тапкыр 1911 нче елның көзендә яңадан университетка укучы итеп алына. Ләкин кинәттән булган үлем аны укуыннан да, революцион эшеннән дә аера. 1912 нче елның 13 нче мартында, кич сәгат 8 дә кинәт үлә. Аны күмгәндә ике меңнән артык халык катнаша. Боларның күпчелеге укучы яшьләр, студентлар булалар. Иптәшләре тарафыннан куелган ленталарда: „Ул үз халкының якты истикбалы булачагына ышану һәм өмет илән китте"[1]) дип язылган була.

М. Гайнуллин.

[1]) „Хөсәен Ямашевны искә төшерү" исме астында „Кояш" газетасында 1913 ел 13 мартта Габдырахман Мостафа имзасы белән басылган.

[2]) „Кояш" 1913 ел, Габдырахман Мостафа истәлеге.

Комсомолның башлангыч һәм урта мәктәптәге эше турында

ВЛКСМ Үзәк Комитетының унынчы пленумы карары

ВЛКСМ Үзәк комитеты пленумы, большевиклар партиясе һәм хөкүмәт җитәкчелеге астында совет мәктәбенең соңгы елларда күп кенә яңа уңышларга ирешүен күрсәтеп үтә.

СССР да ана телендә гомуми мәҗбүри башлангыч белем алу тормышка ашырылды. Барлык баскыч мәктәпләрдә укучыларның саны 1933—34 нче елдагы 23.814 мең кешедән 1938—39 нчы елда 33.965,4 меңгә кадәр үсте. Шәһәрләрдә һәм авылларда 1933—1938 нче еллар эчендә 20.607 яңа мәктәп төзелде, совет укытучылары яш буынны советча тәрбияләүнең куәтле культура көче булып үстеләр.

Шушы уңышлар белән бергә, мәктәпләрдә җидди җитешсезлекләр дә бар. Күп мәктәпләрдә укучыларның бер өлешенең укудан өлгереше, башлыча рус теле һәм математика буенча өлгереш, түбән дәрәҗәдә булуында дәвам итә, бер класста ике ел калу әле бетерелмәгән. Мәктәпләрдә укучыларның дисциплинасызлык фактлары, алар тарафыннан укытучыларга карата ялгыш мөнасәбәттә булу, дәресләргә һәм уку заданиеләренә игтибарсыз карау фактлары, түзеп тора алмаслык фактлар урын алган.

ВЛКСМ Үзәк Комитеты пленумы шушы күрсәтелгән җитешсезлекләр өчен җаваплылык комсомол өстенә төшә дип хисаплый.

Мәктәпне комсомол эшенең әһәмиятле тармагы итеп түгел, ә көндәлек игтибарга һәм кайгыртуга лаеклы булмаган икенче дәрәҗәдәге эш итеп карап, комсомол балаларны уңышлы рәвештә тәрбияләү һәм укыту бурычларыннан шактый дәрәҗәдә читләште, мәктәпләрдә тиешле эш алып бармый.

Әгәр дә комсомол комитетлары мәктәпләрдәге комсомол һәм пионер оешмаларына чын-чынлап җитәкчелек иткән һәм мәктәп мәсьәләләре белән көндәлек рәвештә шөгыльләнгән булсалар иде, мәктәпләр эшендәге күп кенә җитешсезлекләр бетерелгән булыр иде. Һәрбер мәктәп комсомол оешмасының эшенә керү, укудан өлгерешне һәм аңлы дисциплинаны күтәрүдә аңа көндәлек ярдәм итү, мәктәпләрдә, укучыларның җыелышларында, кичәләрендә регуляр рәвештә булу урнына,—комсомол җитәкчеләре бу эшне мәктәп бүлекләренә һәм пионер бүлекләренә ышанып тапшырдылар.

Комсомолның мәктәптә начар эшләве аркасында, укучы комсомолецларның башка укучылар өчен яхшы үрнәк булып хезмәт итмәүләре генә түгел, үзләре укудан өлгермәү фактлары да бар.

Комсомолның күп кенә оешмаларында укытучыга карата ялгыш караш яшәп килә. Укытучыга Совет дәүләте тарафыннан яш буынны коммунистик тәрбияләүнең һәм укытуның мактаулы эше йөкләтелгән. Комсомол оешмаларының укытучы белән даими элемтә тотуларыннан башка мәктәптә эшне уңышлы алып бару мөмкин түгел. Ләкин, укытучыга ярдәм итү, аның белән кулга-кул тотышып эшләү урнына, укудан өлгерешне күтәрүгә һәм дисциплинаны ныгытуга ирешү урнына,—мәктәпләрдәге комсомол оешмалары укытучыдан еш кына аерылалар, аны алыштыралар һәм барлык укучыларның да укытучыга карата дөрес мөнасәбәттә булуларын тәрбияләмиләр.

Комсомолда тормаган укучылар арасында эшләү канәгатьләнмәслек куелган. Төрле түгәрәкләр оештыруда инициативаны үз өстенә алу, укучыларның бөтен массасын комсомолның төрле эшләренә тарту, аларны берләштерү һәм үз артыннан алып бару урнына,—комсомол оешмалары еш кына алардан аерылалар һәм үз эчләрендә бикләнеп яшиләр.

ВЛКСМ Үзәк Комитеты пленумы комсомол комитетларының пионер отрядларына канәгатьләнмәслек җитәкчелек итүләрен аеруча күрсәтеп үтә. Комсомол оешмалары пионер отрядлары белән көндәлек рәвештә шөгыльләнмиләр һәм аларның эшен белмиләр, алар турында каникул көннәрендә генә яки балаларны лагерларга озату алдыннан гына исләренә төшерәләр.

Пионерларга җитәкчелек итүдә күп кенә шаблон һәм формализм бар. Балаларның күп төрле сораулары, аларның яшьләренә карата булган үзенчәлекләре исәпкә алынмый. Пионер отрядларының эше, гадәттә, сборлар үткәрүгә, аның өстенә еш кына эчтәлексез һәм күңелсез сборлар үткәрүгә кайтып кала. Бу нәрсә балаларның инициативасын тарайта һәм аларга үзләренең сәләтләрен күрсәтүгә комачаулый.

Күп кенә пионер отрядларында хәзерлекле вожатыйлар юк. Пионер вожатыйларын сайлап алуның яшәп килә торган системасы—шул мәктәп белән бәйләнеше булмаган һәм педагогия ягыннан хәзерлеге булмаган комсомол работникларын гына читтән тартуга нигезләнгән бу система үзен акламады. Күп кенә мәктәпләрнең тәҗрибәсе өлкән вожатыйлар эшенә мәктәп укытучыларын тарту дөресрәк икәнлеген күрсәтә.

Укучыларның киң массалары фәннең, техниканың, сәнгатьнең, спортның барлык өлкәләрендә үзләренең сәләтләрен күрсәтүгә омтылалар. Балалар арасында гаять күп санда уйлап табучылар, музыкантлар, нәфис сүз осталары, художниклар, спортчылар бар.

Совет мәктәбе балаларның бу инициативасын канәгатьләндерү өчен киң мөмкинлекләр тудырды.

Укучыларның бик күп яклы үзешчәнлекләренә җитәкчелек итү, балаларның үзешчәнлек иҗадына җитәкчелекне үз кулларына алу һәм шуның белән мәктәпләр арасында, укучыларның төрле түгәрәкләре арасында ярышны җәелдерү урнына,—комсомол оешмалары һәм барыннан да элек аларның җитәкчеләре бу эшне икенче дәрәҗәдәге эш итеп хисаплыйлар һәм балалар эшенең күргәзмәләре, смотрлары, балалар олимпиадалары, концертлар һ. б. төсендә балаларның иҗад үзешчәнлекләрен күрсәтүне оештыру турында аз кайгырталар.

ВЛКСМ Үзәк Комитеты пленумы, югарыда саналган җитешсезлекләр, комсомол эшендә мәктәпнең иң мөһим тармак булуын комсомол оешмаларының аңламаулары нәтиҗәсе булдылар дип күрсәтә. ВЛКСМ Үзәк Комитеты пленумы комсомолның мәктәптәге эшенә бәя биреп җиткермәүне кискен рәвештә гаепли.

ВЛКСМ Үзәк Комитеты пленумы карар бирә:

1. Комсомол оешмаларын һәм аларның җитәкчеләрен, — комсомолның мәктәптәге эшенә бәя биреп җиткермәүне бөтен комсомолның эшендәге бу зур җитешсезлекне бетерергә мәҗбүр итәргә. Комсомол оешмалары комсомолның мәктәптәге эшендәге зур җитешсезлекләрне бетерүгә большевикларча керешергә һәм кыска срок эчендә мәктәп комсомол оешмаларының һәм пионер отрядларының эшләрен кискен рәвештә яхшыртуны тәэмин итәргә бурычлылар.

ВЛКСМ Үзәк Комитеты, һәрбер комсомол оешмасының эшенең нәтиҗәләре турында барыннан да элек мәктәптә укуның һәм дисциплинаның ничек куелган булуына карап бәя бирәчәк.

2. Комсомолның республика, край, өлкә, округ, шәһәр, район комитетларына, — мәктәп комсомол оешмалары белән җитәкчелекне тамырыннан ук яхшыртырга тәкъдим итәргә. Комсомолның урындагы оешмаларының җитәкчеләрен,—мәктәпләрдә һәм мәктәптән тыш учреждениеләрдә регуляр рәвештә булырга, укытучыларның һәм укучыларның сорауларына сизгер һәм игтибарлы рәвештә карарга, бөтен эштә аларга булышлык һәм ярдәм күрсәтергә мәҗбүр итәргә. Яхшы һәм отлично өлгерешкә, мәктәптә аңлы дисциплинаны ныгытуга, укучыларның һәр яклап үсүләренә ирешә барып халык мәгарифе органнары белән берлектә, укытучылар һәм укучылар активларын чакырырга, бюроларда һәм пленумнарда мәктәп мәсьәләләрен һәм мәктәп комсомол оешмалары мәсьәләләрен тикшерергә.

3. Комсомол оешмаларын,—укытучыларга карата дөрес булмаган караш фактларын, комсомолның кайбер оешмаларында урын алган бу фактларны бетерергә мәҗбүр итәргә. Укытучыларны мәктәп комсомол оешмаларының эше мәсьәләләрен тикшерүгә тартырга, аларның тәҗрибәсенә һәм белемнәренә таянырга, яш укытучыларның алдынгы өлешен комсомолга тартырга.

4. Укудан иң яхшы өлгереш һәм дисциплина өчен мәктәпләр арасындагы социалистик ярышны барлык чаралар белән җәелдерергә. Шушы теләк белән, укытучыларның район киңәшмәләрендә һәм конференцияләрендә, район мәгариф бүлекләре мөдирләренең отчетлары белән бер рәттән, аерым мәктәпләрнең һәм укытучыларның докладларын тыңлауны файдалы дип санарга. Комсомолның район, шәһәр, өлкә комитетларын,—укытучылар киңәшмәләрен һәм конференцияләрен хәзерләүдә һәм үткәрүдә актив катнашырга һәм алдынгы мәктәпләрнең һәм укытучыларның бу конференцияләрдә күренгән тәҗрибәләрен киң күләмдә җәелдерергә мәҗбүр итәргә.

5. Комсомолның өлкә, шәһәр, район комитетларын,—мәктәпләрнең хуҗалык мәсьәләләрен хәл итүдә актив катнашырга, мәктәпләрне уку әсбаплары, ягулык, инвентарь белән тәэмин итүдә халык мәгарифе органнарына булышлык күрсәтергә мәҗбүр итәргә. Мәктәп ашханәләренең эшләрен, иртәнге ашларның сыйфатын яхшырту чараларын күрергә. Укучылар мәктәптән ерак яши торган авыл җирләрендә аларны транспорт белән тәэмин итүгә ирешергә.

6. ВЛКСМ Үзәк Комитетын, Союзный республикаларның комсомол үзәк комитетларын, өлкә комитетларын, — укытучыларның политик белем дәрәҗәләрен һәм эш квалификацияләрен тагын да күтәрүдә, аларны әдәбият, сәнгать әсәрләре белән, фән һәм техниканың яңа казанышлары белән таныштыруда халык мәгарифе органнарына булышлык күрсәтергә мәҗбүр итәргә.

7. Укучылар арасында иҗади ярышны җәелдерү һәм сәнгатьнең, әдәбиятның, техниканың төрле төрләре буенча аларның сәләтләрен күтәрү өчен, ВЛКСМ Үзәк Комитеты пленумы, халык мәгарифе органнары белән берлектә, район, шәһәр, өлкә күләмендә балалар иҗады күргәзмәләрен, шулай ук балаларның район, шәһәр, өлкә күләмендәге художество үзешчәнлегенә смотрлар үткәрергә тәкъдим итә. Күргәзмәләр һәм смотрлар балаларның барлык күп төрле үзешчәнлек иҗадына комсомолның урындагы оешмаларының ничек җитәкчелек итүләренең күрсәткечләреннән берсе булырга тиешләр.

8. Җимеш бакчалары төзү, шулай ук тәҗрибә участкылары, яшелчә бакчалары, чәчәк бакчалары булдыру буенча Москва, Ленинград һәм башка өлкәләрдәге күп кенә мәктәпләрнең инициативасын якларга. Комсомолның район, шәһәр, өлкә комитетларына, — бу эштә мәктәпләргә барлык чаралар белән булышлык күрсәтергә.

9. Комсомолның район, шәһәр, өлкә комитетларын,—пионер оешмаларының эшләрендәге зур җитешсезлекләрне бетерергә, пионер вожатыйлары сайлап алуның яшәп килә торган системасын үзгәртергә мәҗбүр итәргә. Мәктәпләрдә пионер отрядларының өлкән вожатыйлары, кагыйдә буларак, укытучылар арасыннан һәм һәр хәлдә педагогик хәзерлеге булган кешеләр арасыннан сайланып алынырга тиешләр дип билгеләргә. 3—4 нче классларда пионер отрядларының вожатыйлары булып, кимендә 6—7 класс күләмендә белеме булган комсомолецлар, 5—6 һәм 7 нче классларда пионер отрядларының вожатыйлары булып, кимендә 7—8 класс күләмендә белеме булган комсомолецлар эшли алалар.

10. Мәктәп эше мәсьәләләрен „Комсомольская Правда“ның һәм урындагы комсомол матбугатының канәгатьләнмәслек яктыртуын күрсәтеп, „Комсомольская Правда“ны һәм барлык комсомол газеталары редакцияләрен—алдынгы мәктәпләрнең, укытучыларның, мәктәп комсомол оешмаларының, отличник укучыларның эш тәҗрибәсен киң күләмдә җәелдерүне тәэмин итәргә мәҗбүр итәргә.

11. Барлык өлкә, округ, край комитетларында, союзный республикаларның ВЛКСМ Үзәк комитетларында һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетында әлегә кадәр яшәп килгән укучы яшьләр бүлекләрен һәм пионерлар бүлекләрен мәктәп яшьләренең һәм пионерларның бердәм бүлекләренә берләштерергә.

Врачларның белемнәрен күтәрү институты (Казан) югары квалификацияле маляриалоглар хәзерли. РӘСЕМДӘ: маляриалоглардан бер группа Казан Дәүләт университетында дәрестә, сулдан:—И. В. Талочко (Куйбышев), В. Ф. Курганович (Грузия), Ф. П. Кашеваров (Иваново өлкәсе), Н. Г. Пантелеев (Чиләбе), дәрес уздыручы университет ассистенты Н. А. Зайцева. П. Невзоров фотосы

УКЫТУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯЛӘРЕНДӘ

ЯХШЫ НӘТИҖӘЛӘР

Шушы көннәрдә Теләче районында укытучылар конференциясе булып үтте. Конференция уку елының беренче яртысына йомгак ясап, практик эштә булган зур гына кимчелекләрне ачты һәм киләчәктә аларны бетерү чараларын билгеләде.

РОНО мөдире иптәш Галиуллин, үз докладында, укытучылар конференциягә зур уңышлар белән килүен ачык фактлар белән күрсәтте.

Районның күп кенә мәктәпләре һәм аерым укытучылар уку елының икенче чирегендә аеруча яхшы нәтиҗәләргә ирештеләр. Беренче чиректә башлангыч мәктәпләр буенча өлгереш 60 процент иде. II нче чиректә бу сан 86,9 процентка җитте.

Үз классларында 100 процент өлгереш биргән укытучылар саны да районда шактый күп. Теләчедәге урта мәктәпнең IX-б классы җитәкчесе иптәш Курбатова II нче чиректә 100 процент өлгереш бирүгә ирешә. Мондый уңышларга ирешүчеләр арасында орденлы укытучы Хәбибуллина, Павлов, Һадиев, Гасимов һәм башка иптәшләр бар.

Мәктәпләрдә фәнне үзләштерүдә, укучылар арасында социалистик ярышны җәелдерүдә комсомол һәм пионер оешмалары укытучылар коллективына зур булышлык күрсәтәләр. Бу эш Теләче, Янцевар авылларындагы мәктәпләрдә аеруча яхшы оештырылган. Өлгерешнең башка мәктәпләргә караганда шушы мәктәпләрдә өстенрәк булуы моны ачык раслый.

Районның кайбер мәктәпләрендә әле шактый кимчелекләр дә бар. Кибәч, Олы Норсы, Баландыш авылларында күп кенә балалар укуга бөтенләй тартылмаганнар. Районда 500 бала укудан читтә тора. Ун мәктәптә пионерлар оешмасы бу көнгә кадәр оештырылмаган.

Доклад буенча сөйләүләрдә катнашкан 20 укытучы, эш тәҗрибәләрен уртаклашу белән бергә, кимчелекләрне тиз арада бетерү чараларын да күрсәттеләр.

Г. Сәмигый.

КҮҢЕЛСЕЗ ФАКТЛАР

БУА. (Телефон буенча). 9—11 нче гыйнварда укытучыларның район конференциясе булып үтте. Конференциядә 1939—40 нчы уку елының ярты еллык йомгаклары һәм алдагы бурычлар турында РОНО мөдире иптәш Хөсәеневнең доклады тыңланды.

Доклад буенча фикер алышуларда укыту-тәрбия эшләрендә булган күп кенә җитешсезлекләр күрсәтелде.

Район буенча өлгереш 66,3 проценттан артмый. Кайбер мәктәпләрдә абсолют өлгереш аеруча түбән (Кильдураз урта мәктәбе һәм Аксу ТБУМ е). Татар мәктәпләрендә рус теле фәне буенча өлгереш 20—25 процент кына.

Район мәгариф бүлегенең мәктәпләргә җитәкчелеге канәгатьләнерлек түгел. РОНО работниклары укытучыларга методик ярдәм күрсәтмиләр, мәктәпләрнең көндәлек эшләренә контроль ясамыйлар.

Конференциядә халыкара хәл турында ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Герасимов доклад ясады.

Конференция уку-укыту эшләрен яхшырту буенча конкрет чаралар билгеләде.

С. Вахитов.

Гомуми һәм политик белемне күтәрү—укытучы өчен беренче шарт

Әтнә районында 284 укытучы эшли. Алар арасында үз эшләрендә яхшы нәтиҗәләр бирүче иптәшләр күп. Мәсәлән, Әтнә мәктәбенең уку - укыту бүлеге мөдире иптәш Бахманова Казан Педагогия институтының 3 нче курсын, Олы Мәңгәр авылындагы урта мәктәп директоры иптәш Дәүләтшин Казан Дәүләт университетының II нче курсын читтән торып уку белән тәмамладылар. Башлангыч мәктәп укытучыларыннан Киме авылы укытучысы Сабирова, Бәрәзә авылы укытучысы Шәрәфиев, Әтнә мәктәбеннән Вәлиева, Еникеева иптәшләр педагогия училищесен читтән торып уку белән тәмамладылар. Нәтиҗәдә бу иптәшләр быелгы уку елының беренче чирегендә югары өлгереш бирделәр.

Ләкин укытучылар арасында белемнәрен күтәрү өстендә тырышып эшләмәүче иптәшләр дә бар әле. Олы Мәңгәр авылы укытучылары Тимергалиев, Исмагыйлов иптәшләрне, Иске Кишет авылы укытучылары Абдуллин, Сәмигуллина иптәшләр белемнәрен күтәрү өстендә эшләмиләр.

Совет укытучысы дигән исем—ул, бөек исем. Гомуми һәм политик белемне күтәрми торып, бу бөек исемне аклау мөмкин түгел. „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ басылып чыкканга бер елдан артык вакыт үтте. Бу бөек әсәрне укытучыларның иң зур күпчелеге инде берничә тапкыр укып чыкты һәм конспект төзеде. Ләкин кайбер иптәшләр партия тарихын өйрәнү эшенә керешмәгәннәр дә әле. Болар исәбенә Абдуллин, Шакиров, Ианфелов, Җәләлиева, Нурмехаметова, Хәмзин һәм Вәлиев иптәшләрне кертергә мөмкин. Бу иптәшләр уку елының беренче чирегендә үзләренең идея-политик дәрәҗәләре түбән булуын практик эштә бик ачык күрсәттеләр. Шакиров һәм Абдуллин иптәшләр укыту-тәрбия эшләрен канәгатьләнерлек итеп куя алмаулары өчен эшләреннән алындылар.

Безнең үсеп бара торган социалистик культурабыз совет укытучысының идея-политик дәрәҗәсе югары булуын таләп итә. Совет укытучысының идея-политик дәрәҗәсен күтәрү өчен бездә бөтен шартлар тудырылган. Бу шартлардан файдалана белергә генә кирәк.

Профсоюзларның урыннардагы оешмалары һәм мәктәп дирекцияләре укытучыларның белемен күтәрү белән кызыксынырга һәм аларга ныклы булышлык күрсәтергә тиешләр.

РОНО мөдире *Мөхәммәдиев.*

ЧИТТӘН ТОРЫП УКУЧЫЛАР ЭКЗАМЕННАР ТАПШЫРАЛАР

Казан Дәүләт университетында 1.290 кеше читтән торып укый. Алар өчен беренче гыйнвардан университетта кышкы экзаменнар сессиясе башланды. Экзаменнар бирү һәм лекцияләр тыңлау өчен университетка 1.000 нән артык кеше килде.

Бу елгы кышкы экзаменнар читтән торып укучыларның материаллар өстендә тырышып эшләүләрен һәм яхшы үзләштерүләрен күрсәтә. Экзаменнарны „яхшы“ һәм „отлично“ билгеләренә тапшыручыларның саны үткән елга караганда шактый артты.

Экзаменнар тапшыруда кайбер иптәшләр аеруча яхшы үрнәкләр күрсәтәләр. География факультетының III нче курсында укучы иптәш Мартьянов барлык фәннәрне „яхшы“ һәм „отлично“ билгеләренә тапшырды. Ул, Татарстанда алдынгы укытучыларның берсе булып хисаплана. Иптәш Мартьянов укыту һәм тәрбия эшләрендә дә гүзәл үрнәкләр бирде һәм бирә. Шуның өчен хөкүмәтебез аны орден белән бүләкләде.

Иптәш Гобәйдуллин 4 ел буенча „яхшы“ һәм „отлично“ билгеләренә генә укый.

Физика-математика факультетының IV нче курсында укучы иптәш Абдрашитов (Октябрь районында урта мәктәп укытучысы) барлык фәннәр буенча „яхшы“ һәм „отлично“ билгеләре ала. Читтән торып укучылар арасында мондый иптәшләр күп кенә.

Д. И.



РӘСЕМДӘ: Аерым заказлар буенча күн аяк киемнәр хәзерләү фабрикасының алдынгы стахановчысы М. А. Андронов. Ул, эшләп чыгару планын уртача 300 процент үтәп килә. Н. Галиев фотосы.

ПРОФСОЮЗ ЭШЕ ЯХШЫРА

(2 нче номерлы тегү фабрикасының фабком председателе иптәш Матвеева белән беседа)

— Профсоюз органнарына сайлаулардан соң 6 айдан артык вакыт узды. Бу чор эшебезне яңа баштан кору, масса белән элемтәне барлык чаралар белән ныгыту, алда торган политик-хуҗалык бурычларны үтәү тирәсенә массаны туплау чоры булды.

Без эшне, барыннан да элек, профсоюз эшенә әле яңа гына тартылган яшь кадрларны тәрбияләүдән, аларны практик эшкә өйрәтүдән башлап җибәрдек. Чыннан да, эшебездә төп таянычыбыз булган актив безнең алга конкрет таләпләр куйды. Шуңа күрә дә без профсоюз активын кыска сроклы курслар, семинарлар аша үткәрдек. Аларны профсоюз эше белән яхшылап таныштырдык.

Фабком составына яңа гына сайланган яшь кадрлардан плановик Кац, җаваплы приемщица Нерминова, технолог Азмитов, мастер Ловчева, тегү машинасында эшләүче—стахановчы Дунаева, охрана начальнигы Хәсәнев һәм башка иптәшләр үз эшләрен зур осталык һәм намус белән башкаралар. Алар үзләренә тапшырылган эшне актив белән бергәләп хәл итәләр.

Фабрикада социалистик ярыш һәм стахановчылык хәрәкәте белән без хәзер җиддиерәк шөгыльләнә башладык. Социалистик ярыш договорларының үтәлешен әледән-әле тикшереп торабыз. Нәтиҗә күз алдында: 1939 нчы ел планын 109 процент итеп үтәдек. 1940 нчы елда да коллектив еллык планны вактыннан элек арттырып үтәү өчен намус белән көрәшә. Хәзер бездә стахановчылар саны 700 кешегә җитә.

Производство киңәшмәләрен системалы рәвештә план буенча үткәрәбез. Монда без эшебезгә йомгак ясыйбыз. Ирешелгән казанышларны ныгыту һәм булган кимчелекләрне бетерү буенча конкрет чаралар билгелибез.

Производство планын үтәү өчен көрәштә стахановчылар мәктәбе дә зур урын тота. Без бу мәктәп аша йөзләрчә иптәшләрне стахановча эшләргә өйрәттек һәм өйрәтәбез. Ул социалистик хезмәт мастерларын тәрбияли, аларны эштә чыныктыра.

Фабрикага яңа килгән яшь эшчеләрне профсоюз членлыгына тарту өлкәсендә дә уңышларыбыз зур. Коллективыбыз 100 проценты белән профсоюз членнары.

Безнең культура - тәрбия эшләрен оештыру һәм эшчеләрнең көнкүреш-тормыш шартларын яхшырту өлкәсендә күп эшлисебез бар әле. Фабком тирәсенә тупланган йөзләрчә активистлар белән берлектә бу кимчелекләрне дә бетерербез һәм эшебезне бүгенге көн сорауларына тулы җавап бирерлек итеп оештыруга ирешербез. Моның өчен бөтен мөмкинлекләр бар.

Киров районы, 9 нчы номерлы мәктәптә 3 оборона түгәрәге эшли. РӘСЕМДӘ: врач Д. А. Воронцов противогазны өйрәнү буенча занятие уздыра.

Л. Панов фотосы.

ЛЕНИН КӨННӘРЕ АЛДЫННАН

Кама Тамагы районының хезмәт ияләре Ленин көннәренә эшлекле рәвештә хәзерләнәләр. Предприятиеләрдә, мәктәпләрдә, колхоз клубларында беседалар үткәрелә. Район һәм стена газеталары Ленингә багышланган күргәзмәләр хәзерлиләр. ВКП(б) райкомының парткабинеты В. И. Ленинның тормышы һәм эше турындагы әдәбият һәм документлар күргәзмәсе оештырды. „Иптәш Сталин җитәкчелегендә Ленинсез—Ленин юлы буенча 16 ел" дигән темада колхозларда докладлар үткәрү өчен 30 докладчы билгеләнде.

Райондагы иң алдынгы колхозлардан булган Маркс һәм Ленин исемендәге колхозның алдынгылары җыелышы, гектардан 100 пот иген уңышы алу өчен көрәшүчеләр ярышына кушылырга карар бирде һәм чәчү инвентарьларына ремонт ясауны 21 нче гыйнварга тәмамларга йөкләмә алды. Колхозчылар колхозның ике бригадасына һәм 20 членына Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә катнашу хокукы алу өчен көрәшәләр.

* * *

Ленин көннәрендә Зеленодольски шәһәре предприятиеләрендә һәм учреждениеләрендә „Иптәш Сталин җитәкчелегендә Ленинсез—Ленин юлы буенча 16 ел" һәм „В. И. Ленин тормышындагы һәм эшендәге әһәмиятле моментлар" дигән темаларда беседалар һәм лекцияләр үткәреләчәк.

Парткабинетта, шәһәр клубында һәм шәһәр китапханәсендә фотокүргәзмәләр һәм В. И. Ленин әсәрләренең күргәзмәләре оештырылды. 14 нче гыйнварда партия активы өчен „Лениннең „Дәүләт һәм революция" исемле китабы" дигән темада лекция укылды.

21 нче гыйнварда Париж Коммунасы исемендәге клубта шәһәр советы башкарма комитетының траур утырышы булачак. Бу утырышта партия, профсоюз һәм совет оешмаларының вәкилләре катнашачаклар.

* * *

15 нче гыйнвардан башлап Казанның барлык мех предприятиеләрендә Владимир Ильич Лениннең тормышы һәм эше турында беседалар һәм кычкырып газеталар уку үткәрелә башланды. 19 нчы гыйнварда Мехкомбинатның барлык предприятиеләрендә эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең В. И. Ленин истәлегенә багышланган тулай җыелышлары үткәреләчәк. Мехчылар парткабинетында һәм китапханәсендә В. И. Ленин әсәрләре һәм Ленин турындагы әсәрләр витриналары хәзерләнде.

Ленин әсәрләре татар телендә

Татгосиздат 1939 нчы елда, 51 исемдә, марксизм-ленинизм классиклары әсәрләрен басып чыгарды. Шуларның 19 ы Владимир Ильич Ленин әсәрләре. Яңа чыккан китаплар арасында Лениннең татар теленә беренче тапкыр тәрҗемә ителгән әсәрләреннән „Нәрсә эшләргә?" (13 басма табакта 10 мең данә тиражда басылды) „Ленин ике томлыгы" ның беренче томы (48 басма табакта 10 мең данә тиражда), „Нәрсә ул халык дуслары һәм алар социал-демократларга каршы ничек сугышалар", „Империализм—капитализмның иң югары стадиясе", „Азык налогы турында" һәм башкалар бар.

Болардан тыш Лениннең брошюра, мәкалә һәм речьләре татарчага тәрҗемә ителде. Алар арасында „Учредительное собраниегә сайлаулар", „Социалистик революция һәм милләтләрнең үз билгеләнү хокуклары", „Пролетариат диктатурасы чорының экономикасы һәм политикасы", „Социализм һәм сугыш", „Безнең революциябездә пролетариатның бурычлары", „Россия революциясенең биш елы һәм бөтен дөнья революциясенең перспективалары", „Коммуна истәлегенә" дигән китаплар һәм башкалар бар.

Художество әдәбияты секторы буенча Мирер һәм Баровикның 10 мең тираж белән „Эшчеләрнең Ленин турындагы истәлекләре" дигән китабы һәм балалар—яшьләр әдәбияты секторы буенча Анна Ильинична Ульянованың „Ильичның балалык һәм мәктәп еллары" дигән китабы басылып чыкты.

„Лениннең сайланма әсәрләре ике томлыгы" ның II нче томы, „Бер адым алга, ике адым артка", „Пролетар революция һәм ренегат Каутский", „Маркс—Энгельс—марксизм", „Дәүләт турында", „1905 нче ел революциясе", „Рус социал-демократларының аграр программасы" дигән китаплар (барлыгы 14 исемдә) производствога бирелде. Бу китаплар 1940 нчы елның беренче кварталында басылып чыгачаклар.

Быел Татгосиздат Лениннең әсәрләрен барлыгы 31 исемдә басып чыгарачак. Алар арасында татар теленә беренче тапкыр тәрҗемә ителә торган түбәндәге әсәрләр бар: „Материализм һәм эмпириокритицизм", „1914—18 нче елгы империалистик сугыш", „Икенче интернационалның җимерелүе", „Пролетар партия өчен көрәш", „Яшьләр турында", „Лениннең мәктәп һәм халык мәгарифе мәсьәләләре турындагы мәкаләләре", „Патша Россиясендә эшчеләрнең һәм крестьяннарның хәле". Шулай ук, Лениннең күп кенә әсәрләре икенче тапкыр басылалар.

Быел ВКП(б) тарихын өйрәнүчеләр өчен Ленин—Сталин әсәрләре җыентыгының (I. һәм II нче томнары) тәрҗемәсе хәзерләнә. Җыентык 110 басма табак күләмендә 20 мең данә тиражда басылачак. Художество әдәбияты секторы оригиналь һәм тәрҗемә материаллардан Ленин—Сталин турында әдәби җыентык хәзерли.

Р. Н.

ИРЕКЛЕ СТРАХОВАНИЕ

Дәүләт тарафыннан үткәрелә торган ирекле страхование чараларының көтелмәгәндә бәлә-казага очраган чакта колхозларга һәм колхозчыларга зур ярдәме тия.

Арча районында 1939 нчы елда ирекле страхование эше уңышлы гына үткәрелде. Колхозларда атларның 82 проценты, сыерларның һәм башка терлекләрнең 75 проценты ирекле рәвештә страхованиеләнде. Колхозчыларның үз карамакларында булган терлекләренең һәм йорт әйберләренең дә шактый өлеше страховать ителде.

Арча районында узган ел бәлә-казага очраган колхозларга 55 мең 783 сум, ә колхозчыларга 39 мең 672 сум страхование акчасы түләнде. Шул исәптән: Сталин исемендәге колхоз 4 мең 900 сум, „Кызыл Сәрдә" колхозы 3 мең 400 сум страхование акчасы алдылар.

Йорт әйберләрен һәм каралтыларын ирекле рәвештә страховать итүче колхозчыларга 7 мең сум, гомерләрен страховать итүчеләргә 11 мең 500 сум акча түләнде. Мәсәлән, үзенең гомрен ирекле рәвештә страховать иткән Галимҗанов семьясе 2 мең сум, Трухчеева семьясе 1.000 сум страхование акчасы алдылар.

Ләкин районның барлык колхозларында да ирекле страхование яхшы куелган дип булмый әле. „Субаш-Аты", „Яңа Тормыш", „Утар-Аты", „Кызыл Таң", „Мәдәният", „Амур", „Көтек" колхозлары үзләренең терлекләрен тулысынча страховать итеп бетергәннәре юк.

А. Нәби.

ХАТЛАР ЭЗЕННӘН

„Н. В. Гогольнең сайланма әсәрләре"

21 нче ноябрьдә „Кызыл Татарстан" газетасында басылган Ш. Байчура иптәшнең „Гогольнең сайланма әсәрләре" нә карата тәнкыйте уңае белән Татгосиздатның баш редакциясендә җыелыш уздырылды. Җыелышта Байчура иптәш тәнкыйте тикшерелде. Җыелышта катнашучы редакторлар һәм тәрҗемәчеләр тәнкыйтнең урынлы һәм дөрес язылуын әйттеләр. Тикшерү, тәрҗемәче иптәш Камскийнең генә түгел, редактор иптәш Имамутдиновның да, издательство һәм типографиянең дә хаталарын ачты. Шул уңай белән тәрҗемә һәм аны бастыру практикасы буенча күп кенә тәкъдимнәр кертелде. Хәзер издательство хаталарны булдырмау өчен практик чаралар күрә башлады.

Чит илләрдә

Швеция реакциясе ак финнәргә ярдәмгә „иреклеләрне" ничек туплый

СТОКҺОЛЬМ, 15 гыйнвар. (ТАСС). Нигытмалар төзү өчен соңгы вакытта Швециядә эшсезләр арасыннан Маннергейм Финляндиясенә көчле рәвештә „иреклеләр" туплыйлар. Эшсезләргә пособиеләрне кыскарту һәм җәмәгать эшләрен киметү аркасында, Швециядә эшсезләр саны үсте. Швециядәге реакция, эшсезләрнең авыр хәлләреннән файдаланып, аларны „иреклеләр" отрядларына керергә һәр төрле юллар белән мәҗбүр итә. „Социал демократен" газетасы „Бохуслен районындагы эшсез ташчылардан мең кеше нигытмалар төзү өчен Финляндиягә җибәреләчәк" дип хәбәр итә. Швеция ташчыларына ак Финляндиягә кичекмәстән китәргә тәкъдим итеп, газета „Швециядә эшсез ташчылар саны тиздән ике тапкыр артачак" дип, аларны куркыта.

Ак Финляндиягә ярдәм итү ягында торучылар „иреклеләр" туплауның икенче төрле чараларын да кулланалар—алар ак финнәргә хезмәт иткән өчен күп акча бирергә вәгъдә итәләр. Ләкин шунсы характерлы, Норвегиянең „Тидэнс тайн" газетасының хәбәр итүенә караганда, „ирекле" белән төзелгән договорга „бары тик ул үзенең частенә килгәч кенә", ягъни тупланган кешенең чынлап да Финляндиягә килгән булуы ышанычлы булганнан соң гына „кул куела". Шунлыктан, шул ук газетаның белдерүенә караганда, туплау бюролары „полиция белән бергәләп эшләүләре", һәм „тупланган кешенең мораль хәлен" аның ярдәме белән, белүләре гаҗәп түгел.

„Иреклеләр" туплауда хәрби властьлар гына түгел, дәүләт властьлары да катнашалар. Финанс эшләрен алып баручы Стокһольм губернаторы урынбасары Сундберг күптән түгел генә кайбер учреждениеләрнең җитәкчеләренә хат белән мөрәҗәгать итте. Бу хатында ул, Финляндиягә „иреклеләр" булып барырга теләүче барлык хезмәткәрләргә аларның хәзерге эш хакларының яртысы түләнәчәк, дип күрсәтте.

Америка журналы Советка каршы булган ялган хәбәрләрне фаш итә

НЬЮ-ЙОРК, 15 гыйнвар. (ТАСС). Америка матбугатының һәм радиосының Финляндиядәге вакыйгалар турында ялган хәбәрләр таратулары уңае белән „НЬЮ Мэссэс" журналы Американың күренекле журналисты Джордж Сельдснең мәкаләсен басып чыгарды. Бу мәкаләдә ул болай дип яза: „Журналистика эшендә 30 елдан артык тәҗрибәм бар, ләкин Америка матбугаты һәм радиосы тарафыннан Советлар Союзына карата явыз нияте белән алып барыла торган шундый ялган кампанияне бер вакытта да күргәнем юк иде әле". Сельдс Америка матбугаты тарафыннан ходка җибәрелгән һәр төрле ялган хәбәрләрне, мәсәлән, Совет авиациясе тыныч халыкка бомбалар ташлый, дигән хәбәрләрне һәм башкаларны кискен рәвештә күрсәтеп үтә. Америка матбугаты Совет самолетларының тыныч халыкка атмаганлыкларын бик яхшы белә, ләкин бу ялган хәбәрләрне белә торып тарата, дип яза Сельдс.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

Көньяк Кытайда

Гуандун провинциясендә кытай гаскәрләре Кантоннан төньякта өч юнәлештә һөҗүмне дәвам иттерәләр. Кытай ягыннан алынган хәбәрләргә караганда, һөҗүм итүче частьләрнең сул флангысы 13 нче гыйнварда Кантоннан төньяк-көнбатышка таба 30 километрда урнашкан пунктка барып җиткән. 12 нче гыйнварда Кытай гаскәрләре Кантоннан төньякка таба 40 километрда Синьчән тимер юлы станциясенә налет ясадылар.

Кантоннан төньяк-көнчыгышта кытайлар Цунхуа районында японнарның позицияләренә аталарны яңарттылар. Япон колонналарының берсе Кантонга таба чигенә. Сентраль Ньюс агентлыгы тарафыннан бирелгән мәгълүматларга караганда, японнарның Камамото дивизиясе һәм император гвардиясе, Гуандун провинциясенең Төньяк өлешендәге сугышларда зур югалтулар биргәннән соң, яңа көчләр белән нигытылу өчен Кантонга җибәрелгәннәр.

Үзәк Кытайда

Хубэй провинциясенең көньягында, Тунчан секторында кытай гаскәрләре ике көнлек каты сугышлардан соң Наньбошань һәм Гуминьшаньны алдылар. Бу провинциянең үзәк өлешендә Аньлудан төньяк-көнчыгышта җитди сугышлар бара. 12 нче гыйнварда кытайлар анда японнар отрядын чолгап алдылар һәм тар-мар иттеләр. Суйчжоу секторында кытай частьләре Шилипуны алдылар.

Төньяк Кытайда

Шаньси провинциясенең көньяк-көнчыгышында сугышлар Чжанцзы районында дәвам итә.

„Цзунмейжибао" газетасы тарафыннан бирелгән мәгълүматларга караганда, Шицзячжуаннан 60 километрда, Бейпин—Ханькоу тимер юлында, партизаннар 12 нче гыйнварда тимер юл полотносын шартлаттылар. Поезд һәлакәте нәтиҗәсендә японнарның 100 гә якын солдаты үлгән.

ДАНИЯНЕҢ ҺӘРБЕР ӨЧЕНЧЕ ЭШЧЕСЕ — ЭШСЕЗ

Копенгагин, 15 гыйнвар. (ТАСС). „Политикен" газетасы Даниядә эшсезләр саны үткән елның декабрендә 55.462 кешегә артты. Хәзер Даниянең һәрбер өченче эшчесе—эшсез, дип хәбәр итә.

ЯПОНИЯНЕҢ ЯҢА ХӨКҮМӘТЕ

ТОКИО, 15 гыйнвар. (ТАСС). Домей Цусин агентлыгының хәбәр итүенә караганда, адмирал Ионай җитәкчелегендә яңа кабинет төзү тәмам булган. Бары тик эчке эшләр, сәүдә һәм промышленность министрләре посларына гына кандидатлар юк. Агентлыкның хәбәр итүенә караганда, кабинетка түбәндәгеләр кергән: баш министр—адмирал Ионай Мицумаса, чит ил эшләре министре—Арита Халаиро, Хәрби министр—генерал Хата Сюнроку, диңгез министре вице-адмирал Иосида Дзенго, юстиция министре—Кимура Сетану, мәгариф эшләре министре—Мацуура Цинцэиро (яшрен советник һәм Кюсюда император университетының элекке советнигы), җир һәм урман эшләре министре—Симада Тосио (Сейюкай партиясенең „реформистлар" группировкасы лидерларыннан берсе, 1936 нчы елдагы Хирота кабинетының элекке җир һәм урман эшләре министре), финанс эшләре министре—Сакураучи Юкио (Минсейто партиясе лидерларыннан берсе һәм 1939 нчы елда Хиронума кабинетында элекке җир һәм урман әшләре министре), тимер юллар министре—Мацуно Цурухэй (Сейюкай партиясенең „Ортодоксаль" группировкасы лидерларыннан берсе), колонияләр министре—генерал Койсо Куниаки (Херанума кабинетында элекке колонияләр минстре), элемтә эшләре министре—Кацу Масанори (Минсейто партиясенең җитәкче члены), сәламәтлек саклау эшләре министре—Иосида Сигерү (1934 нче елда Окада кабинетында генеральный секретарь).

Мәгълүм ки, хәрби министр Хата һәм диңгез министре Иосида Абэ кабинетына да кергәннәр иде.

„Англия этәргече".

М. Отаров рәсме (ТАСС фото-клишесе).

ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 15 гыйнвар. (ТАСС). Кичә фронтта әһәмиятле бер нәрсәнең дә булмавы турында хәбәр ителә.

ПАРИЖ, 15 гыйнвар. (ТАСС). Бүген иртә белән игълан ителгән белдерүдә, фронтта „төн тыныч үтте", дип күрсәтелә.

БЕРЛИН, 15 гыйнвар. (ТАСС). Германия армиясе верховный командованиесенең белдерүендә: „Фронтта бер төрле дә аеруча вакыйгалар булмады" диелә.

БЕРЛИН, 15 гыйнвар. (ТАСС). Трансоцеан агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Франция яры буенда Англиянең 4.575 тонна авырлыгындагы „Атлантик Скаут" дигән пароходы баткан.

ЯПОНИЯДӘ ЗУР ПОЖАР

БЕРЛИН, 15 гыйнвар. (ТАСС). Германия информация бюросы, Токиодан көньяк-көнбатышка таба 300 километрда, Сидзуока шәһәрендә гаят зур пожар чыкканлыкны хәбәр итә. 2 меңнән артык йорт, шул исәптән вокзал, почта һәм шәһәрнең барлык мәктәпләре диярлек янып беткәннәр. Пожар вагон төзелеше заводында башланып киткән. Көчле өермә нәтиҗәсендә ут тиз арада шәһәрнең башка кварталларына таралган. Пожарны сүндерүдә шәһәрнең һәм шәһәр бистәләренең барлык пожарныйлары, шулай ук хәрби командалар катнашканнар. Ләкин әле шушы вакытка кадәр утны сүндерергә мөмкин булмаган. Пожар башланганнан соң 7 сәгать үткәч тә шәһәрдә 300 кешенең һәлак булганлыгы мәгълүм булган. Пожардан килгән зарарлар гаят зур.

Чит ил эшләре халык комиссариатының матбугат бүлегенә хат

12 нче гыйнварда мин „Дейли экспресс" редакциясеннән Финляндия мәсьәләсе буенча сорау алдым. Мин бу газетаның Москвадагы хәбәрчесе булып торам. Миннән җавап килгәнне көтмичә, газета, үзенең Москвадагы хәбәрчесенә таянып, 13 нче гыйнварда ялган хәбәр басып чыгарды.

„Дейли экспресс" минем журналистлык намусыма тиеп, һичбер ярамаслык фальсификация методыннан файдаланганлыктан, протест белдереп, бу газетада эшләүдән баш тарттым.

Бүгенге көннән башлап, мине „Дейли экспресс"ның хәбәрчесе дип исәпләмәвегезне сорыйм.

Роберт Магидов.

1940 ел, 15 гыйнвар.

1940 НЧЫ ЕЛДА ЗАЕМНЫҢ БЕРЕНЧЕ ТИРАЖЫ

17 нче гыйнварда Чкалов шәһәрендә Икенче Бишьеллык (дүртенче ел чыгарылышы) заемының 14 нче тиражы уйнала башлый. Бу—1940 нчы елда беренче тираж. Тиражда 196.420.000 сумлык 1.210 мең отыш уйналачак. (ТАСС).

РАЙОН ҮЗӘГЕНДӘ СТАЦИОНАР КИНО

Кызыл Армия районы үзәгендәге культура йортында 1939 нчы елның декабреннән стационар кино эшли башлады. Районның хезмәт ияләре һәм колхозчылары кинога бик теләп йөриләр. Район үзәгенә якын торган авыллардан кино карарга килүче колхозчылар да бик күп була. 9 нчы гыйнвар көнне „Ленин октябрьдә" картинасын 500 дән артык кеше карады.

Культура йортында кино белән бер рәттән күп төрле түгәрәкләр дә эшлиләр.

Һ. Рәшитов.

КАЗАН КИНОСТУДИЯСЕНЕҢ ЭШЕ

Кинохрониканың Казан студиясе 1939 нчы елда 37 киножурнал һәм бер киноочерк чыгарды.

1940 нчы елны киностудия ай саен өчәр журнал чыгарып барачак. Ел башында, „Ленин торган урыннар буйлап" дигән темада тавышлы киноочерк чыгарылачак. Москва киностудиясе бригадасы быел Татарстан республикасының культура-көнкүреш төзелеше өлкәсендәге казанышларын чагылдырган кыска метражлы, тавышлы фильм хәзерләп чыгарачак.

(Тат ТАСС).

Медицина институтының юбилее

Казан Медицина институты үзенең 125 еллыгын бәйрәм итүгә хәзерләнә.

Бәйрәм 28 нче гыйнварда, Кызыл Армия йортының Колонналы залында тантаналы утырыш белән башланачак.

29 нчы гыйнварда юбилейгә багышланган фәнни конференция башлана. Конференциядә СССР ның күренекле галимнәреннән академик А. Д. Сперанский, фәннең атказанган эшлеклесе А. В. Вишневский, СССР фәннәр Академиясенең член-корреспонденты профессор Лаврентьев һәм башкалар катнашачак.

Институтның икенче бинасында юбилей күргәзмәсе ачылачак. Бу күргәзмә институтның тарихын һәм фән өлкәсендәге, укуукыту һәм дәвалау өлкәсендәге казанышларын чагылдырачак.

Күп балалы аналарга бер миллион ярым сум пособие

Чаллы районындагы күп балалы 285 ана һәр ел дәүләттән пособие алып килә. Күп балалы аналарга дәүләт пособиесе бирү турындагы закон чыккан вакыттан алып 1.541.920 сум пособие түләнде. Узган ел 529 мең сум пособие бирелде.

„Коминтерн" исемендәге колхоз члены, 10 бала анасы И. П. Волкова 12 мең сум, элеватор эшчесе А. И. Семенова 18 мең сум пособие алды.

Ворошиловча атучы кызлар

Чаллы районында соңгы вакытта 15 кыз „Ворошиловча атучы" значогына норма тапшырды. Алар арасында „Комсомолец" һәм „Татарстан" совхозлары эшчеләре М. Петрова, А. Большова, М. Гурьянова, И. Зәкиева һәм башка иптәшләр бар.

Шәһәр советы депутаты комсомолка О. Хазова, төз атучы исемен алып, Осоавиахим райсоветының штаттан тыш инструкторы булып эшли.

(ТатТАСС).

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген, 17 нче гыйнварда
КЫЮ КЫЗЛАР
Талон 97.
18 нче гыйнварда көндез һәм кич
ТУКАЙ
Талоннар: көндез 98, кич 99.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 17 нче гыйнварда
Ясалма каучук заводы коллективы өчен спектакль. Талоннар белән кертелми.
Иртәгә көндез һәм кич
БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА
Талоннар: көндез 16, кич 79.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 8 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Тулысынча яңа программа
Москва 4 нче труппасының гастрольләре
Бөтен труппа катнаша.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

Татар Дәүләт Опера театры
(Зур Драма театры бинасында.
Телефоннар: 5—20 һәм 30—78).
19 нчы гыйнварда
Талоннар: 64 һәм 65.
ФАЙДАСЫЗГА САКЛАНУ
Балет 3 пәрдәдә.
Кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Билетлар алдан ЗДТ кассасында һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр сатыла.
Культпоходлар оештыру буенча заявкалар алына.

Н. Александров исемендәге типографиядә кислотадан бушаган, 38 литр сыешлы
БУТЫЛЬЛӘР (зур шешәләр) **САТЫЛА**
Бауман урамы, Матбугат йорты, Телефон 24—82.
2—1

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы художестволы яңа фильм ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	УКЫТУЧЫ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 6, 8 һәм 10 да	Инженер Кочинның ялгышуы
„ЧАТКЫ" 6, 8 һәм 10 да.	УКЫТУЧЫ
„ПИОНЕР" 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Көндезге һәм кичке сеансларда СЕНТЯБРЬДӘГЕ ТӨН
„РОТ-ФРОНТ" 4, 6, 8, 10 да.	ЦИРК
КУЛЬТУРА САРАЕ 4, 7, 9-30 да.	БӨЕК ГРАЖДАНИН (Икенче сериясе)

„ЭЛЕКТРО" КИНОТЕАТРЫ
даими рәвештә эшләп килә торган
ТАНЦЫЛАР МӘКТӘБЕНЕҢ
башлап өйрәнүчеләр, өйрәнүләрен дәвам иттерүчеләр һәм югары тип
группаларына өйрәнүчеләр алу дәвам итә
Группаларга һәр көн көндез 2 сәгаттән кич 10 га кадәр язылырга мөмкин.
Танцыларга өйрәнү эшләрен, танцылар буенча Москва мастерларыннан—Самуил Нальский һәм Таисия Вамбурт алып бара.
Һәр ял көне алдыннан һәм ял көннәрендә танцылар залында кич 10 сәгаттән төнге 1 сәгатькә кадәр теләгән барлык кешеләр өчен танцылар була.
80—1

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 2485 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 213.